**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

№ 20 Биклән авылы «15» ноябрь 2019 ел

2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

«2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге бюджеты хакында» карар проекты буенча Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге халкының фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Биклән авыл җирлеге уставы, «Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге бюджеты хакында» Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Советы карар проекты (2019 елның 11 ноябрендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырылып, халыкка җиткерелгән) буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны 2019 елның 28 ноябреннән дә соңга калмыйча, җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Билгеләргә:

3.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын: 2019 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатьтә;

3.2. халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;

3.3. үткәрү урыны: ТР, Тукай районы, Биклән авылы., Чкалов урамы, 30а. (авыл җирлеге бинасы);

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү, халык тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирү өчен адрес: ТР, Тукай районы, Биклән авылы., Чкалов урамы, 30а (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр).

4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге бюджеты хакында» карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев